СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
« ТИМЯШЕВСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
« ТИМӘШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2024 елның 10 июле №16

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында**

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Ветеринария турында» 1993 елның 4979-1 номерлы РФ Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертергә:

«Йорт хайваннарын һәм кошларын тоту» бүгене 132 пункттан 155 пунктка кадәр төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни ур., 71Д йорт - җирле үзидарә бинасы, Киров ур., 26 йорт –авыл мәдәният йорты бинасы, Нефтепроводчиклар ур., 20 йорт - Ромашкино РНУ БПО, Киров ур., 1А йорт - балалар бакчасы утырышлар залы, д.1А.- «Ласточка» балалар бакчасы бинасы, Лесная ур., 20 адресы буенча урнашкан торак пунктның мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

« Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Х.Х. Сөләйманова

ИНН 1625000493
КПП 164901001